

Армиягә чакырылуга кадәрге яшь-ләрнен «Ватан сакчысы - 2021» кышкы республика спартакиадасынын район этаплары уза.
Темников балалар-яшvсмерләр спорт мәктәбендә, Россия ДОСААФы оешунын 94-еллыгына багышланган, «Ватан сакчысы – 2021» кышкы республика спартакиадасынын зона этабы узган.
Спартакиаданын финалына vтv момкинлеге очен Краснослободск, Теньгушево, Зубово-Поляна, Ельники һәм Темников районнарыннан биш команда коч сынашкан. Ярышлар башланыр алдыннан командаларга техника куркынычсызлыгы буенча инструктаж бирелгән.      Балалар vзләренен сафта әзер-лекләрен физик яктан - перекладинада кvтәрелv, утлы ату - пневматик винтовкадан ату, Калашников автоматын жыю һәм сvтv кvнекмәләрен кvрсәттеләр.
Узган барлык сынаулар нәтижәләре буенча оченче урын Ельники районы командасы яулаган. Икенче урында Явас авылы егетләре. Мактаулы беренче урынны Темников районы алган.
Беренче урынны яулаган команда составында Советлар Союзы герое А.И.Семиков исемендәге Темников урта мәктәбе укучылары Илдус Нураев, Вячеслав Гераськин, Руслан Трегулов һәм капитаннары Артем Шурупов иде. Команданы әзерләvче житәкче – утыз елдан артык хезмәт иткән югары квалификацияле физкультура һәм ОБЖ укытучысы Шамиль Зариф улы Акчурин. Ул Почётная грамота Министерства спорта Республики Мордовия, Грант Главы РМ, Почётная грамота правительства Республики Мордовия, Почётная грамота Министерства просвещения Российской Федерации дигән бvләкләр белән бvләкләнгән. Укучылары да житәкчеләре тосле тырышлар, сынатмаганнар – беренчеләр һәм регион ярышларында да шундыйлар булып калсыннар.
Узган атнада, шулай ук, Тор-беево муниципаль районы адми-нистрациясенен Яшьләр эшләре, физкультура һәм спорт бvлеге инициативасы белән Торбеево урта гомуми белем бирv мәктәбенен спорт залында Армиягә чакырылучы яшьләрнен «Ватан сакчысы - 2021» кышкы респуб лика спартакиадасынын район этабы узган. Спартакиадада жинvчеләргә һәм призерларга Мактау грамоталары һәм истәлекле бvләкләр тапшырылган.

**Наилә НАСЫРОВА**